| | |
|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**Карар** **Решение**

№ 4-24 от «14» ноября 2023 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 28 сентябрендәге № 86-ТРЗ, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 33 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 28 сентябрендәге № 78-ТРЗ, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»2023 елның 2 ноябрендәге № 99-ТРЗ Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2025 елның 15 октябрендәге 4-2 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017 ел, №4-19, 29.06.2018 ел, №10-27, 03.09.2018 ел, № 8-28, 19.11.2018 ел, № 11-29, 28.03.2019 №8-32, 23.07.2019 №17-34, 30.06.2020 №12-39, 10.06.2021 №8-7, 12.11.2021 №13-9, 11.08.2022 ел, № 13-15, 26.04.2023 ел, №18-21, 28.07.2023 ел, № 11-22) карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 9 бүлегенең 9.5, 9.7 пунктларында «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 11 бүлегенең 11.7 пунктында «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 11 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 11.7.1 пункт өстәргә:

«11.7.1. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге статьяның 11.7 пунктында күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

1.4. 23 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 23.1.1 пункт өстәргә:

«23.1.1. Муниципаль хезмәткәр, әгәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, коррупциягә каршы көрәш максатларындагы башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны жайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 — 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аннан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».

1.5. Нигезләмәнең 23.3 пунктының 1 подпунктына «яисә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $13^{-4}$ статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләрен өстәргә.

1.6. Нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.6 пунктында өченче җөмләне төшереп калдырырга;

1.7. Нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.10 пунктын үз көчен югалтты дип танырга;

1.8. Нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 5.13. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, 4 өлешнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү хакында тәкъдим барлык кирәкле документлар белән бергә җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кергән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов